РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ФИНАНСОВО-БЮДЖЕТНАЯ ПАЛАТА ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

улица К.Маркса, дом 19 Б,
город Чистополь,422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФИНАНС-БЮДЖЕТ ПАЛАТАСЫ

К.Маркс урамы, 19 Б нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-30-10, тел/факс 5-16-71, E-mail: chis.fbp@tatar.ru

***№ 54*** **2024 елның 07 ноябре**

***Боерык*** ***Приказ***

«Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының «Авыл җирлекләре бюджетларына административ комиссияләр тарафыннан салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2020 елның 03 мартындагы 18 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында»

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**БОЕРАМ:**

1. Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының «Авыл җирлекләре бюджетларына административ комиссияләр тарафыннан салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2020 елның 03 мартындагы 18 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. авыл җирлекләре бюджетларына административ комиссияләр тарафыннан салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибендә:

2.1 пунктның б) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"б) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә ул азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә;";

2.1 пунктның г) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"г) штрафка тартылган яисә суд тарафыннан карар кабул ителгән, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы чыгуга бәйле рәвештә,

түләтү мөмкинлеген югалткан җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия яисә кичерү турында актлар куллану;";

2.1 пунктның д) пунктчасының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"д) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кайтарганда, күләме банкротлык турындагы эш буенча производство кузгату өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычлар күләменнән артмаган бурыч барлыкка килү датасыннан биш елдан артык вакыт үтсә, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма документны кире кайтару турында карар чыгару;";

2.1 пунктның д) пунктчасының 2 абзацын төшереп калдырырга;

2.1 пунктның д) пунктчасының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яисә банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турындагы гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул итү;";

2.1 пунктның е) пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге боерык нигезләмәләре 2024 елның 13 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Н.А.Карманова